КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 15 март г.Казань № 134

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 – 2023 елларда Татарстан Республикасының авыл җирлекләрендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында, «Мәгариф» милли проектының «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында табигый-фәнни һәм технологик юнәлешле мәгариф үзәкләрендә эшләү һәм эшләтү чараларын гамәлгә ашыру турында» 2020 ел, 25 декабрь, 1191 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы авыл җирлегендә һәм кече шәһәрләрендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында «Үсеш ноктасы» табигый-фәнни һәм технологик юнәлешле белем бирү үзәкләрен төзү һәм эшләү чаралары комплексына («юл картасына») үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 – 2023 елларда Татарстан Республикасының авыл җирлекләрендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында, «Мәгариф» милли проектының «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында табигый-фәнни һәм технологик юнәлешле мәгариф үзәкләрендә эшләү һәм эшләтү чараларын гамәлгә ашыру турында» 2020 ел, 25 декабрь, 1191 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы авыл җирлегендә

һәм кече шәһәрләрендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында «Үсеш ноктасы» табигый-фәнни һәм технологик юнәлешле белем бирү үзәкләрен төзү һәм эшләү чаралары комплексына («юл картасына»), аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 25 декабрь, 1191 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 15 март, 134 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы авыл җирлегендә һәм кече шәһәрләрендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында «Үсеш ноктасы» табигый-фәнни һәм технологик юнәлешле белем бирү үзәкләрен төзү һәм эшләү чаралары комплексы («юл картасы»)

| Т/с | Чара исеме | Җаваплы башкаручы | Нәтиҗәсе | Срогы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Түбәндәгеләрне раслау:<br>«Үсеш ноктасы» табигый-фәнни һәм технологик юнәлешле белем бирү үзәкләрен төзү һәм аларның эшчәнлеге өчен җаваплы төбәк ведомство проект офисы составындагы вазыйфаи затны;<br>«Үсеш ноктасы» табигый-фәнни һәм технологик юнәлешле белем бирү үзәкләре эшчәнлеге күрсәткечләрен;<br>Татарстан Республикасы территориясендә «Үсеш ноктасы» табигый-фәнни һәм технологик юнәлешле белем бирү үзәкләре эшчәнлеге турында бертип нигезләмәне;<br>авыл җирлегендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан, «Үсеш ноктасы» табигый-фәнни һәм технологик юнәлешле белем бирү үзәкләре төзергә планлаштырыла тор- | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы төбәк башкарма хакимият органының боерык бирү характерындагы акты (алга таба – төбәк башкарма хакимият органының боерык бирү характерындагы акты) | X* елның 31 гыйнварыннан соңга калмыйча |

*X – субсидия алу елы.

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | ган гомуми белем бирү оешмалары исемлегеен | | | |
| 2. | Инфраструктура кәгазен формалаштыру һәм килештерү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, федераль оператор | федераль операторның хаты һәм төбәк башкарма хакимият органының боерык бирү характерындагы акты | аерым график буенча |
| 3. | «Үсеш ноктасы» табигыйфәнни һәм технологик юнәлешле белем бирү үзәкләрен төзү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны игълан итү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | сатып алулар үткәрү турында хәбәрнамәләр | Х елның 1 апреленнән соңга калмыйча |
| 4. | «Үсеш ноктасы» табигыйфәнни һәм технологик юнәлешле белем бирү үзәкләрен зоналаштыру проектларын булдыру | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, федераль оператор | төбәк башкарма хакимият органының боерык бирү характерындагы акты | Х елның 1 апреленнән соңга калмыйча |
| 5. | «Үсеш ноктасы» табигыйфәнни һәм технологик юнәлешле белем бирү үзәкләре мәйданчыкларын Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының методик тәкъдимнамәләренә туры китерү эшләре мониторингын үткәрү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы яки федераль оператор тарафыннан билгеләнә торган форма буенча | Х елның 25 августы, алга таба – ел саен |
| 6. | «Үсеш ноктасы» табигыйфәнни һәм технологик юнәлешле белем бирү үзәкләре эшли башлау | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмати яктырту | Х елның 1 сентябре |
| 7. | «Үсеш ноктасы» табигыйфәнни һәм технологик юнәлешле белем бирү үзәкләрен төзү һәм аларның эшчәнлеге күрсәткечләрен үтәү буенча квартал саен мониторинг үткәрү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | мониторинг йомгаклары буенча федераль операторга хисап | Х елның 1 октябре, алга таба – 2 ел эчендә квартал саен |